ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

Тел., факс: (8-85595) 5-19-69. Leninogorsk.Ikmo@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 04 июле № 1020

Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 703 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру турында актны рәсмиләштерүгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 703 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру турында актны рәсмиләштерүгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.4.3. Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп планлаштыруны тәмамлауны раслаучы кабул итү комиссиясе акты расланган (имзаланган) көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча килештерүне гамәлгә ашыручы башкарма комитетның вәкаләтле кешесе, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларын кулланып, хокукларны теркәү органына электрон формада мөрәҗәгать итүченең үзгәртеп планлаштырылган бинага (үзгәртеп планлаштырылган биналарга)хокукын дәүләт кадастр исәбен яки дәүләт кадастр исәбен һәм дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру турында кабул итү комиссиясе актының, үзгәртеп планлаштырылган биналарның техник планының һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны килештерү турындагы карарның (карар кабул итүне раслаучы документ) мондый гаризасына кушымта белән, шул исәптән гариза бирүченең күчемсез милеккә хокукларны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә яңа биналар барлыкка килгән очракта дәүләт теркәвенә алу өчен дәүләт пошлинасы түләү турындагы мәгълүматны да кертеп гариза җибәрә.  Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында 13.07.2015 ел, 218-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлеше, 25 статьясында каралган нигезләр буенча дәүләт кадастр исәбен һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыруны туктатып торган очракта, бинаны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле зат дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыруны карамыйча яки туктатып тормыйча документларны кире кайтару сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле, шул исәптән гариза бирүчедән (ул вәкаләтле заттан) хокукларны теркәү органына тапшыру өчен күчерелә торган документлар һәм (яисә) үзгәртеп планлаштырыла торган бинаның техник планын сорый..

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар өчен ачык булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Галимова Л.М.
5-44-72